ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

05.06.2024 г. Казань № 31-15/кс-2024

«Кайбыч муниципаль районының «Кайбыч торак-коммуналь хуҗалыгы» МУП өчен су агызуга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Салкын су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендәге тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салынулы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 05.06.2024 №12-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Су агызуны тәэмин итүне гамәлгә ашыручы Кайбыч муниципаль районының «Кайбыч ТКХ» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Кайбыч ТКХ» МУП) өчен ташландык су агызуга әлеге карар кушымтасы нигезендә календарь бүленгән тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2024 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Су агызуны гамәлгә ашыручы «Кайбыч ТКХ» МУП ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2023 елның 26 гыйнварындагы 108 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә, чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы Л.В. Хабибуллина

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
05.06.2024 № 31-15/кс-2024
карарына кушымта

Ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы «Кайбыч ТКХ» МУП өчен ташландык су агызуга календарь буенча бүленгән тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Су агызуга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м | |
|---|---|---|---|
| | | 05.06.2024 № 31-15/кс-2024 карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2024 кадәр | 01.07.2024 башлап 31.12.2024 кадәр |
| | Кайбыч муниципаль районы | | |
| 1 | «Кайбыч ТКХ» МУП* | 81,69 | 81,69 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Отдел организации, контроля и сопровождения
принятия тарифных решений Государственного
комитета Республики Татарстан по тарифам